Һәр кешенең йөрәгенә якын, җанына җиңеллек бирә торган яраткан урыны була.

Минем өчен ул – туган авылым.

Авылымны ике яктан җиләк-җимешкә бай матур таулар, калкулыклар кочаклап алган. Без һәр елны Кала тавы, Чияле тауларына җиләккә йөрибез, җәен-көзен гөмбә җыябыз. Талгын җил искәндә, болын өстенең дулкынлануыннан күзең ала алмый торасың. Нинди генә чәчәкләр юк анда!










**Татарстан җиренең иң матур ягын**
**күрәсегез килсә,**
**безнең авылга килегез.**

Минем хезмәттәшләрем





# Укытучы... Нинди бөек бу сүз!



# Безнең тату гаилә





# Минем педагогик эшчәнлегем












03/11/2010 12:33 PM

20шт.



## Минем мәктәбем

Безнең Карасу урта мәктәбе зур һәм матур. Монда килгән һәрбер кунак мәктәпкә соклана, хәйран кала. Чөнки мәктәп һәрьяктан үзенә тартып тора. Андагы матур-матур гөлләр дисеңме. Кунаклар кайсы гына ел фасылында килмәсеннәр, безнең мәктәп һәрвакыт матур, чиста һәм якты. Безнең Карасу мәктәбе һәрбер йоланы, бәйрәмне үткәрә.

Мәсәлән, 26 нчы март театр көне булып билгеләнә. Менә бу театр көне дә безнең мәктәпне читтә калдырмады. Бу көнне мәктәбебездә Туфан Миңнуллинның "Бәхетле кияү" исемле спектакле куелды. Спектакльдәге рольләрне үзебезнең мәктәп укучылары башкардылар. Алар чын артистларча уйнап дан казандылар. Бу киләчәк буын артистларыбыз: Мөнирә—Ваһапова Фәридә, Нури— Зәйниев Илгиз, Нәфига—Нуретдинова Гөлфизә, Харис—Хәсәнов Рузил, Гөлбикә—Минеголова Ләйсән, Исмәгыйль—Җамалиев Марсель. Алар шундый килешле итеп уйнадылар, нәкъ чын артистлар диярсең. Ә зал шыгрым тулы иде. Нишләп тулы булмасын, театр бит! Миңа бу спектакль бик ошады, чөнки мин үзем дә театр-спектакльләр карарга яратам. Шуның өчен яраткан мәктәбем укучыларына һәм аларның җитәкчеләре татар теле һәм әдәбияты укытучысы Розалия Зөфәр кызы Габделвәлиевага газета аша бик зур рәхмәтемне җиткерәсем килә. Аларга укуларында, эшләрендә зурдан-зур уңышлар телим. Мондый укытучылар һәм укучылар булган вакытта, безнең мәктәп беркайчан да сынмас, сыгылмас һәм һәрчак үрнәк булыр.

**АБДУШЕВА Рузилә,**
**Карасу урта мәктәбенең VII сыйныф укучысы.**

*Туфан Миңнуллинның « Бәхетле кияү» драмасыннан күренеш*





*Туфан Миңнуллинның "Әлдермештән Әлмәндәр"драмасы*







*Ләбиб Леронның «Яңа ел биштәре» ннән күренеш( 5 нче сыйныф укучылары)*

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!